**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ БОЕРЫК

17.02.2021 № 123

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 13.09.2016 ел, № 837 карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнгән Р. М. Гибатдиновның бәяләмәсе нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 13 сентябрендәге 837 номерлы «Нурлат муниципаль районында баланс комиссиясен төзү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

10 пунктны 2 нче кушымтада түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «10. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе һәм утырышта катнашучы барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерү вакыты-өч эш көне эчендә.»;

2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә: «14. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия утырышында тавышларның тигезлеге булганда рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.».

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 17 февралендәге 123 номерлы карарына
1 нче кушымта

Нурлат муниципаль районында Баланс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Хәмзин Рәфис Рафик улы | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Исмәгыйлева Лилия Дамир кызы | - Нурлат муниципаль районы «Финанс-бюджет палатасы» МКУнең исәп-хисап бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килештерү буенча); |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Шәмсетдинов Руслан Ринат улы | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| Сәгыйрова Фәнүзә Вәлимөхәммәт кызы | - Нурлат муниципаль районы «Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча); |
| Сәйфетдинова Зәринә Ринат кызы | - Нурлат муниципаль районы «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча); |
| Титарева Олеся Александровна | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Ибраһимова Марина Вячеславовна | - Нурлат муниципаль районы «Контроль-хисап палатасы» МКУ рәисе |
| Хасанова Фәния Минсәгыйрь кызы | - «Нурлат шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге »ДКУ директоры |

Нурлат муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре директорлары (килешү буенча).